КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 декабрь г.Казань № 1057

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1276 нчы; 2022 ел, 22 июль, 713 нче; 2023 ел, 25 август, 1019 нчы; 2023 ел, 6 октябрь, 1255 нче; 2025 ел, 21 июль, 536 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

икенче абзацта «$6^1$» саннарын «$6^2$» саннарына алмаштырырга;

«в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Контроль объектларын зыян (зарар) китерү рискы категорияләреннән берсенә кертү, шулай ук элегрәк контроль объекты кертелгән зыян (зарар) китерү рискы категориясенә үзгәреш кертү Инспекция карары буенча федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрына белешмәләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Югары риск категориясенә кертелгән лицензия контроле объектлары өчен әлеге Нигезләмәнең 27 пунктында күрсәтелгән планлы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү вакыты ике елга бер планлы контроль (күзәтчелек) чарасы йә елга бер мәҗбүри профилактик визит тәшкил итә.

Чираттагы календарь елга контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү планына кертү өчен лицензия контроле объектына карата соңгы тапкыр планлы контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү тәмамланган датадан башлап әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок чыгу, ә мондый контроль (күзәтчелек) чарасы элек үткәрелмәгән булса, лицензия бирү датасыннан өч ел узу нигез булып тора.»;

15 пунктта «түбән риск категориясендәге» сүзләрен «урта, уртача һәм түбән риск категорияләренә» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Лицензиат «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша консультация үткәрү турында гариза бирергә мөмкин.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы нигезендә уздырыла.

Профилактик визит нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсенә җәмәгать бәяләмәсе бирелми.

Профилактик визит лицензиат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә яисә, үзара дистанцион хезмәттәшлек чараларын файдаланып, шул исәптән видео-конференц-элемтә аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка аның эшчәнлегенә йә аның карамагындагы контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе турында, риск категориясен киметү буенча тәкъдим ителә торган ысуллар турында, тиешле риск категориясенә кертелүенә карап, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль (күзәтү) чаралары төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында мәгълүмат бирелә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын риск категорияләренә кертү өчен кирәкле мәгълүмат җыя һәм контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.»;

түбәндәге эчтәлекле $26^1$ пункт өстәргә:

«$26^1$. Мәҗбүри профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның $52^1$ статьясы нигезендә уздырыла.

Урта яки уртача риск категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата мәҗбүри профилактик визитлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән вакыт ешлыгында үткәрелә.

Түбән риск категориясенә кертелгән лицензия контроле объектларына карата мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелми.

Мәҗбүри профилактик визит лицензиатның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында Инспектор, кирәк булганда, тикшерү, кирәкле документларны таләп итү, инструмент белән тикшерү, сынау, экспертиза ясауны башкара.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында карау, экспертиза үзара дистанцион хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видео-конференц-элемтә, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визит кысаларында тикшерү үткәргәндә фотога төшерү һәм видеога яздыру «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып башкарыла.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле $26^2$ пункт өстәргә:

«$26^2$. Лицензиат инициативасы буенча профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның $52^2$ статьясы нигезендә уздырыла.

Профилактик визит кысаларында лицензиатның ризалыгы белән Инспектор инструмент белән тикшерү, сынау үткәрә.

Лицензиат профилактик визит барышында алган аңлатмалар һәм тәкъдимнәр тәкъдим итү характерында була.

Профилактик визит барышында ачыкланган лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр лицензиатларга бирелә алмый.

Профилактик визит үткәрелгәндә лицензия контроле объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә ачыктан-ачык турыдан-туры зыян (зарар) китерү куркынычы тудыруы яисә мондый зыян (зарар) китерелүе ачыкланган очракта, Инспектор контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карар кабул итү өчен бу хакта мәгълүматны инспекция башлыгына (җитәкче урынбасарына) кичекмәстән җибәрә.»;

28 пунктта:

«Контроль (күзәтчелек) чарасы» сүзләре алдына «Лицензиат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тота торган» сүзләрен өстәргә;

«лицензия таләпләренең үтәлешен күзәтү һәм күчмә тикшерү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.;

30 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) инструмент белән тикшерү.»;

32 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) документлар таләп итү.»;

38 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һәркем файдалана торган (чикләнмәгән затлар даирәсе өчен ачык булган) җитештерү объектларында күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин:»;

дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инструмент белән тикшерү (видеоязма кулланып).»

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

39 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39. Лицензия контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 1, 3 – 9 пунктларында, 60 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында һәм 66 статьясындагы 12 өлешендә каралган нигезләр буенча уздырыла.

Гражданнардан үзләренең бозылган хокукларын яклауга (торгызуга) бәйле мөрәҗәгатьләр (гаризалар) кергәндә контроль (күзәтчелек) чарасы, прокуратура органнары белән килештерелмичә, бу турыда лицензия контроле объекты урнашу урыны буенча прокуратура органына 24 сәгать эчендә хәбәр итеп уздырыла.

Инспекция, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кергәндә һәм лицензия таләпләрен бозуларны булдырмау һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар күрергә кирәк булган очракта, планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын кичекмәстән (әлеге белешмәләр кергәннән соң 24 сәгать эчендә) уздыруга керешә, бу хакта лицензия контроле объекты урнашкан урын буенча прокуратура органына, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 5 өлешендә каралган документларны шул ук срок эчендә җибәреп, хәбәр итә. Бу очракта лицензиатка планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы уздыру турында хәбәр ителмәскә мөмкин.

Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы төрен үткәрү һәм сайлау турында карар кабул иткәндә зыян (зарар) китерү рискын бәяләү максатларында Испекция әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә лицензия таләпләрен бозу рискы индикаторлары белән эш итә.»;

түбәндәге эчтәлекле $40^1$ пункт өстәргә:

«$40^1$. Әгәр урнашу (эшчәнлек башкару) урыны буенча лицензиат булмауга бәйле рәвештә, яисә лицензиат тарафыннан эшчәнлек фактта башкарылмауга бәйле рәвештә, яисә лицензиатның контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү яки тәмамлау мөмкин булмауга китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү мөмкин булмаса, вәкаләтле вазыйфаи зат, Инспектор тарафыннан тиешле акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча, лицензиатка карата шундый ук контроль (күзәтчелек) чарасын лицензиатка алдан хәбәр итмичә һәм прокуратура органнары белән килештермичә үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

41 пунктның өченче абзацындагы беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Лицензия таләпләрен бозу дәлилләрен теркәү өчен үз карамагындагы фотога төшерә, аудиога һәм видеога яздыра торган теләсә нинди техник чара, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасы кулланылырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле $41^1$ пункт өстәргә:

«$41^1$. Инспекция визиты, күчмә тикшерү үзара дистанцион хезмәттәшлек чараларыннан файдаланып, шул исәптән видео-конференц-элемтә аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 30 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында, 32 пунктындагы «а», «б» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән контроль (күзәтчелек) гамәлләр үзара дистанцион хезмәттәшлек чараларыннан файдаланып, шул исәптән видео-

конференц-элемтә аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Тикшерү (күзәтчелек) чарасы кысаларында инспекция визиты, урынга барып тикшерү рәвешендә башкарылганда фотога төшерү һәм видеога яздыру «Инспектор» мобиль кушымтасы ярдәмендә башкарыла.»;

44 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44. Акт мондый чара уздыру тәмамланган көнне контроль (күзәтчелек) чараны үткәрү урынында яисә, әгәр актны мондый чара уздыру урынында төзү 248-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән сәбәпләр аркасында мөмкин булмаса, әгәр актны рәсмиләштерү өчен башка тәртип 248-ФЗ номерлы Федераль законда яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнмәгән булса, мондый чара уздыру тәмамланган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү урынында акт төзү мөмкин булмаган очракта, мондый чараны үткәрү тәмамланган көндә 248-ФЗ номерлы Федераль законның 87 статьясындагы 3 өлеше нигезендә лицензиат актка кул куймый һәм, акт контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында урнаштырылган һәм бу хакта 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешенең 2 пунктында каралган тәртиптә хәбәрнамә алынган очракта, актны алган дип санала..»;

47 пунктта «һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

50 пунктта:

беренче абзацта «Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инспекция башлыгының карарына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Инспекция башлыгы тарафыннан карап тикшерелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 54 пункт өстәргә:

«54. Инспекциянең вазыйфаи заты карарына, актына, күрсәтмәсенә, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять судка кадәрге шикаять буенча мәгълүмат системасында (дәүләт мәгълүмат системасының ярдәмче системасында) теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турындагы карарга карата шикаять иң күбе биш эш көне эчендә карап тикшерелә.»;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

икенче абзацта «күпфатирлы йортлар белән» сүзләреннән соң «, шулай ук кайнар су белән тәэмин итү һәм (яки) җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәтүләрне башкару күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең уртак мөлкәте составына керә торган җиһаз кулланып гамәлгә ашырыла торган күпфатирлы йортлар белән» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «үтәлмәгән, закон көченә кергән» сүзләрен «өч һәм аннан артык закон көченә кергән» сүзләренә алмаштырырга, «карар» сүзен «карарлар» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян

итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче, тугызынчы, унбишенче, егерме дүртенче, егерме бишенче, утыз алтынчы – кырык дүртенче, илле өченче, илле дүртенче, илле җиденче, илле сигезенче, җитмешенче – җитмеш икенче абзацлары 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Күпфатирлы йортлар белән
идарә итү буенча эшмәкәрлек
эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк
дәүләт лицензия контроле турындагы
нигезләмәгә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 8 декабрь, 1057 нче
карары редакциясендә)

Лицензия контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган лицензия таләпләрен бозу рискы индикаторлары

1. Өч ай дәвамында гражданнан яки күпфатирлы йорт бүлмәләре милекчеләре булып торган оешмадан, күпфатирлы йорттагы бүлмәдән файдаланучы гражданнан алынган белешмәләр (мәгълүмат), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат һәм торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә тотылучы зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүмат туры килмәү (дөрес булмау) фактлары биш тапкырдан күбрәк булуы ачыклану.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә лицензия нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр (алга таба – лицензиат) тарафыннан Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү кагыйдәләрен һәм Җылыту чорына әзерлекне тәэмин итүне бәяләү тәртибен раслау турында» 2024 елның 13 ноябрендәге 2234 номерлы боерыгының 17 пункты нигезендә җылыту сезонына әзерләнгәндә кимчелекләр бетерелмәү турында акт керү.

3. Татарстан Республикасы Рәисенең Мәгълүмат-аналитика идарәсе тарафыннан әзерләнгән массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә Татарстан Республикасы халкының кәефен атна саен мониторинглау нәтиҗәләре буенча бер күпфатирлы йортта яшәүчеләрнең күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы зат тарафыннан өч ай рәттән йорт тиешенчә карап тотылмавына карата биштән артык шикаяте ачыклану.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә өч ай рәттән бер үк күпфатирлы йортта лифт һәм (яки) лифт җиһазы берничә (ике яки аннан да күбрәк) тапкыр туктау очраклары (өченче затларның хокуксыз гамәлләренә бәйле рәвештә лифт туктау очракларыннан тыш) турында мәгълүмат керү.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә элемтә операторыннан күпфатирлы йортның уртак мөлкәте объектларында элемтә челтәрләрен монтажлаганда, эксплуатацияләгәндә һәм демонтажлаганда элемтә операторының һәм лицензиатның үзара хезмәттәшлеге турында билгеләнгән таләпләр лицензиат тарафыннан бозылу хакында мәгълүмат керү.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә өч ай рәттән бер үк күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә караган газ белән тәэмин итү объектларында берничә (ике һәм аннан да күбрәк) тапкыр авария хәлләре булу турында мәгълүмат керү.

7. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әзерләнгән халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең (коммуналь хезмәтләр, күпфатирлы йорт белән идарә итү, күпфатирлы йортны карап тоту һәм ремонтлау) сыйфатын бәяләү күрсәткечләренә ай саен анализ ясау нәтиҗәләре буенча күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затны бәяләүнең уртача күрсәткече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүне оештыру һәм уздыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1319 номерлы карары белән расланган Халыкка хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүне оештыру һәм уздыру тәртибе нигезендә кимендә өч бал тәшкил итүен ачыклау.

___